ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әлки муниципаль районы
Аппак авыл җирлеге
Башкарма комитеты

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Аппаковского сельского поселения
Алькеевского муниципального района

Адресы: 422888, ТР, Әлки районы,
Аппак авылы, Тынычлык урамы,1й.
тел./факс 8(84346) 76-443

Адрес: 422888, РТ, Алькеевский
район, с. Аппаково, ул.Мира. д.1
тел./факс 8(84346) 76-443

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　Аппак ав.　　КАРАР

2025 елның "09" июне　　№ 8

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Аппак авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында**

06.10.2003 елның 131-нче Федераль Законы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 27.12.2018 елның 489-нчы Федераль Законы «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Аппак авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. Файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. Халык күпләп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарда, борындыкларда һәм тезгендә аларның хуҗалары күзәтүе астында:

- Аппак авылының көнчыгыш өлеше, Урман урамыннан 100 метр ераклыкта;
- Каракүл авылының көнчыгыш өлеше, Мәктәп урамыннан 200 метр ераклыкта;
- Иске Тумба авылының көнчыгыш өлеше Урман урамыннан 200 метр ераклыкта.

Бу территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү» дигән язулы табличкалар урнаштырырга.

2.Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru хәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлки муниципаль районының
Аппак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе　　И.Х.Әбҗәббарова